КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 16 декабрь г.Казань № 1239

Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының финанс органнары хезмәттәшлеге регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының финанс органнары хезмәттәшлеге регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән хезмәттәшлек иткәндә Регламенттан файдалануны тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 16 декабрь, 1239 нчы карары белән расланды

Чираттагы финанс елына һәм план чорына
Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә бюджетара
мөнәсәбәтләрне формалаштыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгы белән Татарстан Республикасы муниципаль районнарының
һәм шәһәр округларының финанс органнары хезмәттәшлеге
регламенты

1. Бу Регламент чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының финанс органнары (алга таба – бюджетара мөнәсәбәтләр, финанс органы) хезмәттәшлеге тәртибен билгели.

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын төзү тәртибе турында» 2008 ел, 28 март, 206 нчы карары белән расланган Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын һәм Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проектын төзү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, финанс органнарына чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджетларны формалаштыруның сценарие шартларын (шул исәптән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә эшләнгән Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразы буенча төп күрсәткечләрне үз эченә алган) (алга таба – сценарие шартлары), индекс-дефляторларны җиткерә.

Бюджетларны формалаштыруның сценарие шартлары Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты составына керә торган барлык бюджетлар өчен бердәй булып тора һәм Татарстан Республикасы Президенты белән килештерелә.

3. Финанс органы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына түбәндәге документларны тапшыра:

чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы муниципаль районының һәм шәһәр округының берләштерелгән бюджетының салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәре фаразын (алга таба – салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәр фаразы);

чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы муниципаль районының һәм шәһәр округының берләштерелгән бюджетының иң чик база бюджет ассигнованиеләре фаразын (алга таба – иң чик база бюджет ассигнованиеләре фаразы);

бу Регламентның 4 пунктында күрсәтелгән нигезләрне раслый торган документларны.

4. Иң чик база бюджет ассигнованиеләре фаразын формалаштырганда агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы муниципаль районының һәм шәһәр округының берләштерелгән бюджетының бюджет ассигнованиеләре (муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләреннән һәм табигатьне саклау чараларын тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләреннән башка) нигез итеп алына; алар бу Регламентның 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан җиткерелгән индекс-дефляторларны кулланып, агымдагы елның 1 гыйнвары хәленә карата җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен тормышка ашыруга бәйле чыгым йөкләмләрен финанслар белән тәэмин итүгә карала.

Муниципаль юл фондын формалаштыру өчен иң чик база ассигнованиеләре фаразы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $179^4$ статьясындагы 5 пункты нигезендә билгеләнә.

Табигатьне саклау чараларын тормышка ашыру өчен иң чик база ассигнованиеләре фаразы әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү, гомумтаралган файдалы казылмалар чыгаруга салым, табигатьне саклау законнарын бозган өчен штрафлар, әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны каплау турындагы дәгъвалардан керемнәр, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны ирекле каплаганда түләнә торган түләүләр рәвешендә җирле бюджетка керә торган керемнәр күләмендә билгеләнә.

Иң чик база ассигнованиеләре фаразы түбәндәге нигезләр буенча төгәлләштерелергә мөмкин:

гамәлдә булу вакыты агымдагы финанс елы белән чикләнгән яисә чираттагы финанс елында һәм план чорының беренче елында бетә торган чыгым йөкләмәләрен төшереп калдыру;

җирле үзидарә органнарының, муниципаль учреждениеләрнең функцияләрен һәм (яки) вәкаләтләрен үзгәртү, аларны үзгәртеп оештыру (бетерү);

агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының файдалануга кертелгән объектлар һәм учреждениеләр эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итүгә акча бүлеп бирү турындагы карарлары кабул ителгән булса, муниципаль учреждениеләрне һәм муниципаль милектәге объектларны файдалануга тапшыру;

Россия Федерациясе законнарына үзгәреш кертү;

муниципаль мәгариф оешмаларында белем алучыларның һәм тәрбияләнүчеләрнең контингенты санын үзгәртү;

Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан аерым карарлар кабул итү.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы бу Регламентның 3 пункты нигезендә тапшырылган салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәр фаразларын, иң чик база бюджет ассигнованиеләре фаразларын сценарие шартларына туры килүкилмәвен карап тикшерә.

Бюджетларның иң чик база ассигнованиеләре фаразлары бу Регламентның 4 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча төгәлләштерелүе исәпкә алынып карала.

Әлеге карап тикшерү йомгаклары буенча салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәр фаразларын, сценарие шартлары буенча формалаштырылган иң чик база бюджет ассигнованиеләре фаразларын килештерү беркетмәсе рәсмиләштерелә.

Иң чик база бюджет ассигнованиеләре фаразларының сценарие шартлары буенча формалаштырылган салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәр фаразларыннан артып китүе бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына.

Сценарие шартлары буенча формалаштырылган иң чик база бюджет ассигнованиеләре фаразыннан артыграк чыгымнар бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алынмый һәм Татарстан Республикасы Президентына карауга җибәрелә торган мәгълүмат составына кертелә.

6. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга финанс ярдәме күрсәтү өлешендә бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштыру, Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән бюджетара трансфертларны бүлү кагыйдәләре һәм методикалары һәм алар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә бирелә торган бюджетара трансфертлар формаларын кулланып, җирле бюджетлар балансслылыгын (кытлыксызлыгын) тәэмин итү кирәклеген исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

7. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетын формалаштыру бу Регламентның 4 – 6 пунктлары нигезләмәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

8. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты параметрлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының эш планы нигезендә карап тикшерелә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан хупланган күрсәткечләр Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар проектын алга таба эшләү һәм детальләштерү өчен нигез булып тора.